| | |
|---|---|
| СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
| Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700 | Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700 |

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**30 июль, 2026 ел** **№ 83**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының аерым карарлары үз көчләрен югалткан дип тану турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында» 2025 елның 19 маендагы 633/о номерлы боерыгын раслауга бәйле рәвештә, Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

1.1 «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында» 2020 елның 23 сентябрендәге 6 номерлы карары;

1.2 «Биектау муниципаль районы Советының 2020 елның 23 сентябрендәге 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 28 июнендәге 93 номерлы карары.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына мәгълүматны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында актуальләштерүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында

http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов